СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

6 нчы март, 2024 ел Алабуга шәһәре №332

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 26 февралендәге 157 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 декабрендәге 121-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2008 елның 26 февралендәге 157 номерлы карары белән расланган Алабуга муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7.2 статьяның 9 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Класс чины бирү көне булып класс чины бирү турында карар кабул ителгән көн санала.».

1.2. 7.2 статьяның 15 өлешен төшереп калдырырга.

1.3. 7.2 статьяның 18 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Муниципальхезмәткәргә класс чины бирү турында карар, әлеге статьяның 11 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарәнең органына яисә вазифаи затына барлык кирәкле документлары булган классы

чин бирү турында карар кабул ителгән көннән, бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш:

1.4. 10 статьяны түбәндәге редакциядә 2.1 өлеш һәм 2.2 өлешләр белән тулыландырырга:

«2.1. Муниципаль хезмәткәрләргә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, мондый белешмәләрне мәҗбүри тапшырган очракта, йә ялган булган белешмәләрне тапшыру муниципаль хезмәткәрне, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, эштән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора

2.2. Муниципаль хезмәткәрләргә әлеге Нигезләмәнең 2.1 өлешендә күрсәтелгән белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.».

1.5. 12.1 статьяны түбәндәге редакциядә 1.1. өлеше белән тулыландырырга:

«1.1. Муниципаль хезмәткәр «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгәне һәм бурычларны үтәмәгәне өчен, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү ажардан бәйсез булган хәлләр тикшерүе тарафыннан «Ришвәтчелеккә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә таныла икән ришвәтчелеккә каршы тору максатында җаваплылыктан азат ителә.»;

1.5. 16.1 статьяда «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы» сүзләрен «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа»» дәүләт мәгълүмат системасы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль корылыш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Комиссия рәисе урынбасары Р.Л. Исланов